ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　　　　　　　　　　　　　КАРАР

2024 елның «21» маеннан　　　　　　　　　　　　　№ 144

Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итү өлкәсендә Яңа Чишмә муниципаль районы хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2017 елның 14 сентябрендәге 466 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 14 августындагы 569 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында бюджетара мөнәсәбәтләрне формалаштырганда исәпкә алына торган гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итү өлкәсендә Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетларының хезмәт өчен түләү чыгымнары күләмен билгеләү методикасына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 10 маендагы 315 номерлы карарын нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итү өлкәсендә муниципаль берәмлек хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2017 елның 14 сентябрендәге 466 номерлы карарына (Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының

2018 елның 9 гыйнварындагы 1 номерлы, 2020 елның 30 октябрендәге 271 номерлы, 2022 елның 10 октябрендәге 283 номерлы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

күрсәтелгән карар белән расланган гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү өлкәсендә муниципаль берәмлек хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдә:

II бүлекнең 1 таблицасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1 таблица

| № т/б | Хезмәткәрләрнең вазыйфалары | Вазыйфаи окладның күләме, сумнарда |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1 | Оешма җитәкчесе | 25 014 |
| 2 | Оператив дежур торучы | 19 242» |

III бүлектә:

4 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«4. дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләр белән эшләгән өчен ай саен өстәмә түләү - вазыйфаи окладның «0,3» күләмендә сүзләрен, вазыйфаи окладның «5» проценты сүзләренә алыштырырга.

Дәүләт серен тәшкил иткән белешмәләр белән эшләгән өчен күрсәтелгән айлык өстәмә законнарда билгеләнгән тәртиптә рөхсәт язуын рәсмиләштерү шарты белән даими нигездә дәүләт серен белгән хезмәткәрләргә түләнә.»;

2. Әлеге карар 2024 елның 1 июленнән үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына (икътисад буенча) йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Фасахов